**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_07.04.2022__ _258-п___

Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү Комиссиясе турында нигезләмә раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 796 номерлы, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның 2021 елның 26 октябрендәге 19 номерлы «Файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү, файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү турында таныклык бирү һәм файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү турында таныклыкка үзгәрешләр кертү тәртибен раслау хакында»гы боерыгы, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча Комиссия төзергә.

2. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү комиссиясе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү комиссиясе составын.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гойбәдуллинга йөкләргә.

Министр А. В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 7 апрелендәге 258-п номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү комиссиясе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) үз эшчәнлегендә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, «Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына, җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсенә караган Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.2. Комиссия Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан төзелә.

1.3. Комиссия Россия Табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 26 октябрендәге 796 номерлы, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның 19 номерлы боерыгы белән расланган Файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү, файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү турында таныклык бирү һәм файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү турында таныклыкка үзгәрешләр кертү тәртибенең 3 пунктында күрсәтелгән очракларда Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләүне гамәлгә ашыра.

## 2. Комиссиянең функцияләре

Министрлыкка йөкләнгән бурычлар нигезендә Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча гаризаларны һәм кушымта итеп тапшырылган документларны карый;

- Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү яки гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләүдән баш тарту турында карар чыгара.

## 3. Комиссиянең составы һәм аның эшен оештыру

3.1. Комиссия составына Министрлык җитәкчеләре, Министрлыкның минерал-чимал һәм су ресурслары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәләре башлыклары һәм белгечләре, Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты вәкиле (килешү буенча) керә. Комиссия саны 12 кеше тәшкил итә.

3.2. Комиссия әгъзалары түләүсез нигездә эшлиләр.

3.3. Комиссия эшен Комиссия рәисе җитәкли.

3.4. Комиссия рәисе булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

3.5. Комиссия рәисе:

- комиссия утырышын җитәкли һәм үткәрә;
- комиссиянең җаваплы сәркатибен билгели;
- тәкъдим ителгән документларны Комиссия тарафыннан карау нәтиҗәләрен килештерә.

3.6. Комиссиянең оператив эшенә түбәндәгеләр җитәкчелек итә:

- Комиссия рәисе урынбасары;
- Комиссиянең җаваплы сәркатибе.

3.7. Комиссия утырышында җаваплы сәркатип булмаган очракта, Комиссия рәисе Комиссия әгъзалары арасыннан җаваплы сәркатипне билгели.

3.8. Комиссиянең җаваплы сәркатибе:

- Комиссия эшчәнлеген алып баруны оештыра;
- Комиссиянең эш планнары проектларын эшләүне тәэмин итә;
- Комиссия рәисе белән килештереп, Комиссия утырышын оештыра;
- Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;
- Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

## 4. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү

4.1. Комиссия утырышлары турыдан-туры һәм (яки) видео-конференц-элемтә рәвешендә үткәрелә.

4.2. Комиссия утырышлары гариза кергән көннән алып 15 эш көненнән дә артмаган чорда уздырыла.

4.3. Комиссия сәркатибе гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар һәм белешмәләр нигезендә Комиссия утырышының көн тәртибе проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

4.4. Комиссия сәркатибе комиссиянең барлык әгъзаларына аларның электрон почтасына Комиссия утырышының көн тәртибе проектын һәм аның утырышын үткәрелүе турында Комиссия утырышы көненә кадәр 7 эш көненнән дә соңга

калмыйча хәбәр җибәрә.

4.5. Комиссия утырышын үткәрү турында хәбәрдә аның утырышын үткәрү датасы һәм урыны, Комиссия әгъзаларының утырышта катнашу ысулы (турыдан-туры һәм (яки) видео-конференц-элемтә кулланып) турында мәгълүмат булырга тиеш.

4.6. Комиссия сәркатибе комиссия утырышына кадәр 1 эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия әгъзаларына аларның электрон почта адресларына видео-конференц-элемтә кулланып, Комиссия утырышына тоташу өчен мәгълүмат җибәрә.

4.7. Гаризаларны һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны караганда Комиссия әгъзалары Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирергә яисә аларның һәркайсы буенча тавыш бирүдән тыелырга, гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларның һәм белешмәләрнең эчтәлеге белән танышырга, Комиссиянең башка әгъзаларына сораулар бирергә хокуклы.

4.8. Комиссия утырышы Комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булган очракта хокуклы була.

4.9. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы, ә ул булмый торганда, Комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

4.10. Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Комиссия утырышын билгеләнгән көнне үткәрүгә комачаулаучы шартлар барлыкка килгәндә яисә Комиссия утырышы өчен кворум булмаса (ә ул булмаса – Комиссия рәисе урынбасары) Комиссия рәисе тарафыннан утырышны уздыру вакытын, ләкин 5 эш көненнән дә артык булмаган чорга гына, күчерү турында карар кабул ителә.

4.11. Гаризаларны һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4.12. Комиссия карары Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан барлык әгъзалар тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе (яисә Комиссия утырышын үткәргән рәис урынбасары) тарафыннан утырыш уздырылган көннән 3 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

4.13. Гомумтаралган файдалы казылма ятмасын ачу фактын билгеләү турында таныклык бирү һәм гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү турындагы таныклыкка үзгәрешләр кертү тәртибе Министрлык боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында билгеләнгән.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2022 елның 7 апрелендәге 258-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү буенча Комиссия составы

| | |
|---|---|
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары – Комиссия рәисе |
| Чинарев Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе – Комиссия рәисе урынбасары; |
| Гафуров Рәсим Вилдан улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгече – комиссия сәркатибе |
| Ахманова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының углеводород чималы геологиясе бүлеге җитәкчесе |
| Васильева Татьяна Леонидовна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе |
| Вахитов Самат Таһир улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе |
| Галимов Азат Нургали улы | Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча геология һәм лицензияләү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Лукина Людмила Александровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе |
| Мөхәммәтшин Ренат Нурислам улы | Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану департаменты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Полушин Владислав Леонидович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмат-геология ресурслар һәм геология тирәлеген күзәтү бүлеге җитәкчесе |
| Чеснокова Ирина Валерьевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе |
| Шутникова Светлана Анатольевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе |